Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Мәмәшир авыл җирлеге Советы
КАРАР

18 февраль, 2026 ел № 7

Кукмара муниципаль районы Тәмәй торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Тәмәй авылы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2025 елның 29 октябрендәге 2 номерлы Мәмәшир авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мәмәшир авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

2026 елның 2 мартында 16 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Тәмәй авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыены нәтиҗәләре турында» 2025 елның 29 октябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Тәмәй авылы, Ленин урамы, 2А адресында урнашкан мәчет бинасында уздырырга.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«1. «Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Тәмәй авылы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2025 елның 29 октябрендәге 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар преамбуласындагы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы: И.Г. Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702